# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Айбаш авыл җирлеге Апсабаш торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

21 нче ноябрь 2025 нче ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 нче елның 20 нче мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 нче елның 28 нче июлендәге 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Уставының 24 нче статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советының 23.10.2019 елның 162 номерлы "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2025 нче елның 21 нче ноябрендә 10 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Сез, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең Апсабаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, МХО да катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 нчы елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?" дигән мәсьәлә буенча беркетмә төзелде:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

"РИЗА" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 18 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 10 кеше, бу 55,5 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 10 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Апсабаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2026 нчы елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлегенең Апсабаш авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, МХО да катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салым акчаларын 2000 (ике мең) сум күләмендә кертергә.

3. 2026 нчы елда МХО да катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (3 кеше) үзара салым түләүне азат итәргә.

4. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Биектау муниципаль районы
Айбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Сафиуллин